**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 9 август

№ 548

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 18 апрель, 246 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 18 апрель, 246 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 96 нчы; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2010 ел, 20 апрель, 278 нче; 2010 ел, 15 июнь, 477 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 24 март, 217 нче; 2011 ел, 12 август, 663 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 753 нче; 2011 ел, 31 октябрь, 899 нчы; 2012 ел, 27 апрель, 329 нчы; 2012 ел, 31 август, 743 нче; 2013 ел, 26 март, 203 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 831 нче; 2013 ел, 14 декабрь, 987 нче; 2013 ел, 31 декабрь, 1136 нчы; 2014 ел, 16 апрель, 249 нчы; 2015 ел, 25 февраль, 112 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5.4.18 – 5.4.21 пунктчалар өстәргә:

«5.4.18. Идарә башлыгы урынбасары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген боерыгы белән раслый.

5.4.19. Идарәгә беркетелгән процессларны (ярдәмче процессларны) үтәү стандартларын боерыгы белән раслый һәм аларның үтәлешен тәэмин итә;

5.4.20. Төп нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә идарә башлыгы урынбасары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында Идарә буенча нигезләмәне, шулай ук эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән төп күрсәткечләренә бәйле стимуллаштыручы түләүләр күләмен исәпләү тәртибен билгеләү турында нигезләмәне боерыгы белән раслый;

5.4.21. Идарә өчен билгеләнгән төп нәтиҗәлелек күрсәткечләре һәм хезмәт законнары нигезендә үз карамагындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән контрактлар (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков